ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **К А Р А Р**

16.05.2024 | № 444

## «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы кысаларында 2024 елның II кварталына торак биналарның бер квадрат метры бәясен раслау турында

«Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын, «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру максатларында һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә торак урыннарның квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча уздырылган тикшеренүләр нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы кысаларында 2024 елның II кварталына торак урыннарның бер квадрат метры бәясен 109 829, 33 сум (йөз дә тугыз мең сигез йөз егерме тугыз сум утыз өч тиен) күләмендә расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф.Шәйдуллин